**СОВЕТ СЕЛО-АЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422721, Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с. Алат, ул.Первомайская,32

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАТАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422721, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алат авылы, Первомай ур.32

Тел./факс: +7(84365) 63-2-25, e-mail: Salat.Vsg@tata

## Р Е Ш Е Н И Е

**от 24.11.2015 ел** **№ 15**

### Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлегенең бюджеты турында 2016 елга

**Статья 1**

1. Алат авыл җирлеге бюджетының 2016 елга төп характеристикаларын расларга:
1) Алат авыл җирлеге бюджетының гомуми керем күләме 2474 сум,208 мең сум.;
2) Алат авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2474,208 мең сум.
3) Алат авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләме 0 мең сум.
2. Алат авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга: -2016 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

**Статья 2**

1.2016 елның 1 гыйнварына Алат авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә. 2.Алат авыл җирлеге муниципаль бурычның иң чик күләмен билгеләргә
- 2016 елда-0 мең сум күләмендә;

**Статья 3**

Алат авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

**Статья 4**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2016 елга Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

**Статья 5**

1. Алат авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген һәм кодларын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
2. 5 нче кушымта нигезендә Алат авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары, баш администраторлар исемлеген расларга.

**Статья 6**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне раслау турында" 2007 ел, 30 нчы август, 429 нчы номерлы карары: - 2016 елга әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә;
2. Алат авыл җирлеге чыгымнарының ведомство структурасын расларга: - 2016 елга әлеге

карарга 7 нче кушымта нигезендә;
3.2016 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0 мең сум күләмендә расларга.

**Статья 7**
Алат авыл җирлегенең җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен исәпкә алырга:
- 2016 елга 859,3 мең сум күләмендә;;

**Статья 8**
Алат авыл җирлегенең җирлек бюджетларының балансльлыгын тәэмин итү буенча чараларга ярдәм итү өчен дотацияләр күләмен исәпкә алырга:
-2016 елга 4,9 мең сум күләмендә;;

**Статья 9**
Алат авыл җирлегенең Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен субвенция күләмен исәпкә алу: -2016 елга 22,0 мең сум күләмендә;;

**Статья 10**
Алат авыл җирлегенең хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция күләмен исәпкә алу:
-2016 елга 73,5 мең сум күләмендә.;

**Статья 11**
Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Торак капиталь ремонт буенча вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү өчен җирлекләргә муниципаль район бюджетына күчерелә торган башка бюджетара трансфертлар күләмен раслау турында" 2008 ел, 30 декабрь, 988 нче карары мая:
-2016 елга 390,2 мең сум күләмендә.;

**Статья 12**
Алат авыл җирлегенә халык саны буенча финанс ярдәменең район фондыннан дотацияләр күләмен исәпкә алырга:
-2016 елга-17,5 мең сум.;

**Статья 13**
Алат авыл җирлеге башкарма комитеты 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел. шулай ук аларны тотуга чыгымнар да каралган.

**Статья 14**
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Биектау районы буенча территориаль бүлеге органы төзелгән килешүләр нигезендә Биектау муниципаль районы Алат авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**Статья 15**
Әлеге карар ТР Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

**Статья 16**
Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Алат авыл җирлеге башлыгы
Биектау муниципаль районы А.Ш.Шакиров